ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 13 октября 2016 г. г. Казань № 260

«Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен раслау турында»гы Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 16 июлендәге 195 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ санлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен камилләштерү максатларыннан

б о е р а м:

1. «Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен раслау турында»гы Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 16 июлендәге 195 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 бүлекнең 3.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«3.2. Дәүләт комитетының акт проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен Дәүләт комитетының җаваплы структур подразделениесе, юридик бүлеккә карау өчен юнәлтелгән көнгә туры килгән эш көнендә эксперт бәяләмәсен юнәлтү өчен адресны күрсәтеп аны ведомствоара электрон документлар әйләнеше аша тариф чишелешләрен оештыру, тикшерү һәм кабул итү бүлегенә җибәрә.

Шулай ук тариф чишелешләрен оештыру, тикшерү һәм кабул итү бүлеге акт проектын эксперт нәтиҗәләрен юллау өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын да), коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча

бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм кабул итүне туктату көннәрен күрсәтеп, акт проектын сайтта урнаштыра.».

2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының структур подразделениеләре җитәкчеләренә җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис вазифаларын башкаручы А.Л. Штром